СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

27.05.2024 № 46/3

На №__________ от______________

# КАРАР

**«Тукай муниципаль районының муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затлары, муниципаль хезмәткәрләре хезмәтенә түләү системасы турында» «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 29 декабрендәге 28/2 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстмәләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 24 апрелендәге 281 номерлы, 2018 елның 14 июнендәге 481 номерлы, 2018 елның 17 октябрендәге 940 номерлы, 2018 елның 29 декабрендәге 1320 номерлы, 2021 елның 17 ноябрендәге 1087 номерлы, 2021 елның 13 декабрендәге 1222 номерлы, 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы, 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), район Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Тукай муниципаль районының муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затлары, муниципаль хезмәткәрләре хезмәтенә түләү системасы турында» «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 29 декабрендәге 28/2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 2 пунктчасында «12 688» саннарын «13 323» саннарына алыштырырга;

2 бүлек 1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затның (җирлек башлыгы) хезмәтенә түләү айлык акчалата бүләкләү формасында башкарыла:

| Вазыйфа исеме | Айлык акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек Башлыгы | 40 515 |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары | 36 462 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 36 462 |

4 бүлек 2 пунктта «12 688» саннарын «13 323» саннарына алыштырырга, «2023 елның 1 январеннән» сүзләрен «2024 елның 1 июленнән» сүзләренә алыштырырга;

4 бүлек 3 пункт 1 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

муниципаль хезмәтнең билгән вазыйфасына бәйле рәвештә вазыйфаи оклад:

| **Вазыйфа исеме** | **Тапкырлау коэффициенты** (өченче төркем) | **Айлык вазыйфаи оклад күләме** (сум) |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 3,00 | 39 969 |
| Совет аппараты җитәкчесе | 2,77 | 36 905 |
| Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары | 2,77 | 36 905 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 2,72 | 36 239 |
| Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе (ФБП, Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы) | 2,71 | 36 106 |
| Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары | 2,46 | 32 775 |
| Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) | 2,06 | 27 446 |
| Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары | 1,86 | 24 781 |
| Район Башлыгы ярдәмчесе | 1,7 | 22 650 |
| Баш белгеч | 1,52 | 20 251 |
| Әйдәүче белгеч | 1,43 | 19 052 |
| Башка җирле органының әйдәп баручы белгече | 1,43 | 19 052 |
| 1 категорияле , 2 категорияле белгеч, белгеч | 1,28 | 17 054 |

4 бүлек 3 пункт 4 пунктчада «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар һәм икътисадый сәясәт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары

Р.И. Закиров